**Каюм Насыйри исемендәге X регионара фәнни-эзләнү укулары**

# *Юнәлеш: Туган якны өйрәнү*

Тема: **Каюм Насыйриның ”Татар этнографиясе материалларына нигезләнеп, Исергәп авылының борынгы милли киемнәрен өйрәнү**




Исергәп урта гомуми белем бирү мәктәбенең XI сыйныф укучысы Ибраһимова Ләйсән Равил кызының фәнни-эзләнү эше

Фәнни җитәкче: татар теле һәм әдәбияты укытучысы Нәгыймова Римма Илдус кызы

# Фәнни-эзләнү хезмәтемнең планы

1. К.Насыйри хезмәтендә милли киемнәр турында.
2. Фәнни хезмәтләрдә татар милли киемнәре турында.
3. Исергәп авылында милли киемнәр.

# Максат һәм бурычлар

- 1.  Каюм Насыйриның  “Татар этнографиясе материаллары”н җентекләп өйрәнү.
- 2. Ир-атлар һәм хатын-кызларның кием аермалыкларын тикшерү.
- 3. Борынгы татар милли киемнәренең тегелеше, кию урыннары турында күбрәк мәгълүмат туплау.
- 4. Фәнни хезмәтләрдән  борынгы татар киемнәрен  күзәтү.
- 5. Журналлардан, интернет сайтларыннан милли кием үрнәкләрен җыю.
- 6. Исергәп урта мәктәбенең “Туган якны өйрәнү” музееның “Борынгы авыл “ экспозиция  материаллары белән танышу.
- 7. Яшьтәшләремдә милли киемгә ихтирам һәм хөрмәт хисләре  уяту.





# *I бүлек*

**Борынгы татарларда кием -салым**






Мин үз хезмәтемдә татар халкының борынгы киемнәрен К. Насыйриның “Татар этнографиясе материаллары” хезмәтеннән өйрәндем. Татар мөселманнарның киемнәре бик күп төрле һәм башка халыклардан аерылып та тора. Аеруча авыл халкы киемнәренең төрлелегенә игътибар иттем. Киемнәрне авыл халкы күбрәк үзе эшкәртеп теккән, хатын-кызлар чигеп, бизәп, күз явын алырлык, гасырлар үтсә дә, кыйммәтен югалтмаган милли киемнәрне җитештергәннәр. К.Насыйри хезмәтен өйрәнү үзебезнең авыл борынгылары киемнәренә кызыксыну уятты. Музей материалларын тагын да тулыландыру өчен зур эш алып барырга кирәклеген дә аңладым. Интернетта да милли киемнәр турында бай материал урнаштырылуына сөендем, чөнки теләгән һәрбер укучы аннан кирәкле мәгълүмат алырга мөмкин. Этнограф, галим хезмәтендә татарның борынгы киемнәренә мондый мөнәсәбәт белдерелә:

Белгән кеше бар микән: бу татар мөселманнарның киеменең формасы кай заманадан бирле калган икән? Татарда бар кием: күлмәк, ыштан, камзул, казаки, җилән, чапан һ.б. Бу киемнәрнең бәгъзесе бар, башка халыкта һичберәүдә күренми. Һичбер халыкның киеменә охшамый. Бу якын тирәдәге халыкларда ирләр күлмәге күбрәк озынлыгы тезгә җитәр-җитмәс буладыр, җиңел ситсадан яки бүздән, һәркем үзенең теләгәненә күрә.



Иң астан кия торган киемдер, күлмәк өстеннән, урысларның жилеты урынына. Якалы була, алдан төймәлиләр биш я алты төймә белән һәм кесәләре була. Ул камзулның тагы бер төрлесе була кыска җиңле, җиңе терсәгенә җитәр-җитмәс. Ул камзул күп кешедә әдрәстән я бикасаптан була.

Дәхи казаки дигән кием попларның полукафтаны кебегрәк була; озын була, тездән була, тездән түбән, тубыкка чаклы, һәртөрле нәрсәдән. Элгәре күбрәк әдрәстән, бикасаптан буладыр инде.



Ул кәләпүш асыл Бохардан, сартлардан чыккан нәрсә. Ул кәләпүш фарсыча сүз: кәлә-баш мәгънәсендә, пүш-япмак мәгънәсендә; баш капкачы дигән кебек була.Ул кәләпүшне башка бертөрле ефәк материядән, хәтфәдән ясыйлар әйләнәсенә ука тотып. Ефәк чуклы була түбәсендә. Аны һәм яхшы итеп эшлиләр, ул кәләпүшне әдрәстән, бикасаптан, ситсадан вә һәртөрле материядән.



Чалбар кияләр.. Махсус татар чалбары була,урыс чалбарына башкарак; төбе бик киң була, балак очлары таррак; бу чалбарны балагын чыгарып йөреп булмый. Балакны чыгарып йөри күп кешеләр. Һәртөрле халыкта булса кирәк, хатын-кыз киеме белән ирләр киеме бер төрле түгел. Ирләр киеме белән хатыннар киеме арасында күп аерма бар. Инде хатын-кыз киемнәре менә: күлмәк, ыштан, читек, башмак, кәвеш, камзул, тун, яулык, шәл.



Хатыннар күлмәге бик озын була, җиргә чаклы, аякны капларлык; шәригать буенча хатыннар киеме шулай кирәк. Хатыннар күлмәгенең итәге ике кат була. Элгәре күлмәкнең итәге башка төстән була торган иде, инде күлмәге белән бер төсле була. Ситса була, унике аршын яки унөч аршын ситса кирәк.





# *II бүлек*

**Фәнни хезмәтләрдә татар милли киемнәре турында**





**Татар халкының милли киемнәре.**

Татарлардан рухи мирас белән бергә матди мәдәният өлкәсенә караган мирас та калган. Шундыйларның берсе — халыкның өс киеме. Өс киеменең бик борынгы төрләре, әлбәттә, безгә килеп җитмәгән. Ә инде җиткән кадәресе халкыбызның кабатланмас иҗади көчкә ия булуын күрсәтә. Гасырлар буена халык бу эшкә үзенең кул көчен генә түгел, бәлки матурлыкка омтылышын, хыялын, эстетик зәвыгын да салган.

# Татар халык киеме

Бүгенге көндә безгә мәгълүм традицион-гадәти өс киемнәре — эчке һәм тышкы киемнәр, баш һәм аяк киемнәре, хатын-кызларның бизәнү әйберләре. Элек-электән бирле бер комплекска кергән кием төрләре, формалары һәм колориты буенча үзара яраклашып, бер стильне тәшкил иткәннәр. Гадәти өс киеме шактый тотрыклы булып, аның яңаруы-үсеше халыкның үз гореф-гадәтләренә һәм көнкүрешенә яраклашу төсендә барган. Шуңа күрә кием, гадәттә, кешенең тышкы кыяфәтенә милли төс биргән. Киеменә карап аның кайсы халык яки нинди этник группа вәкиле икәнен белергә мөмкин булган. Көндәлек һәм бәйрәм киеме, бай һәм ярлы кешенең киеме дә бары тик тукымалары, бизәнү әйберләренең сыйфаты белән генә аерылган.

**Өс киемнәре**

Күлмәк белән ыштан.

Кием комплексының нигезен күлмәк белән ыштан (ирләрдә соңрак — чалбар да) тәшкил итә.

Борынгы стильдәге ирләр күлмәген мамык, җитен, киндер җебеннән тукылган

материядән текkәннәр

(ефәк күлмәк-ыштан кияргә ирләргә шәригать кушмаган).





## Күлмәк итәге

Хатын-кызлар күлмәгенең итәген төрлечә бизәү дә борынгыдан ук килә. Күлмәкнең үзен өй тукымасыннан текхән очракларда аның өске итәген кызыл, ал, яшел, зәңгәр төстәге фабрика тукымасыннан эшләгәннәр.

## Ыштан

Эчке киемнең икенчесе — ыштан. Аның да гадәттәге өлгесе ирләр һәм хатыннар өчен бер булып, безнең халыкның борынгы тормыш-көнкүрешенә (идәнгә, сәкегә аяк бөкләп утыру һ.б.) җайлашкан форманы тәшкил итә.

## **Тун**


Татар халкының өс-киемнәреннән саналган тун белән толыпны да күрсәтеп китәргә кирәк. Аларны иләнгән сарык яки төлке тиресеннән тукыма белән тышлап эшләгәннәр. Туннарны өч билле һәм туры аркалы итеп теккәннәр.

## **Түбәтәй**

Татар халкының баш киемнәре дә гаять үзенчәлекле. Борын-борыннан ирләр өйдә түбәтәй кияргә яратканнар. Тик керәшен татарларында гына, христиан динен кабул иткәннән соң, ислам атрибуты дип каралган түбәтәй аларның кием комплексыннан төшеп калган.

**Калфак**

Калфакның төрләре хәйран күп. XIX йөзнең урталарына кадәр зур, чуклары аркага (яки иңгә) төшеп торган капчык калфаклар була. Аларны төрле төстәге җептән яки тукымадан ясаганнар. Ак җептән бәйләнгән озын калфаклар барлык төркем кызларына да хас бу.



**Хатын- кыз бүреге**


Хатын-кызлар борын-борыннан бүрек тә кигәннәр. Әмма ул баш киеме үз эченә йомшак түбәле мех кырпулы бүрекне дә, кирәчле (каркаслы), кырыйларына тәңкәләр, асыл ташлар куеп эшләнгән яки челтәрләр белән бизәлгән очлы такыя бүрекне дә ала.

## Яулык

Яулык һәм тастар терминнары астында төрле формадагы бөркәнчекләр бар. Яулык — борынгы төрки термин. Бу термин белән, югарыда күреп узганча, кечерәк аскы баш яулыгы да, зур бөркәнчек кушъяулыклар да атала.

## Шәл

XIX йөзнең ахыры — XX йөз башларында традицион бөркәнчекләр урынына фабрика эшләп чыгарган яулык һәм шәлләр керә. Ләкин традицион баш киеменә хас җирле үзенчәлек билгеләре хатыннарның фабрика яулыгын бәйләү ысулларында бүгенгә кадәр чагыла.




## Хатын-кызлар бизәнү әйберләре

Хатын-кызларның өс һәм баш киеме белән бизәнү әйберләре дә тыгыз бәйләнгән. Борынгы бабаларыбыздан килгән ювелирлык осталыгы шәһәрләрдә һәм кайбер зур авылларда XX йөзнең башларына кадәр яшәп килә. Катлаулы ысуллар белән (бөтерү, бөртекләү, каралту, гравирлау, инкрустацияләү) зиннәтләп эшләнгән хатын-кыз бизәнү әйберләре төрле музейлардагы татар коллекцияләре арасында бүген дә күп санда сакланган. Аларны өч төркемгә бүлеп карарга була: баш, муен-күкрәк һәм кулга бәйле бизәнү әйберләре.





<u>III бүлек</u>



**Исергәп авылында борынгы милли киемнәр**





# Исергәп авылы ничек барлыкка килгән соң?

- 1552 елны явыз Иван канга батырып, Казан ханлыгын яулап алганнан соң, Баулы, Ютазы төбәкләрендәге җирләр күчмә тормышта яшәгән башкортларга рәсми рәвештә беркетелә. Чыгышы белән башкортларның бөрҗән кабиләсеннән булган Исергәп исемле кеше үз ыруы вәкилләре белән 18 гасыр башында хәзерге Исергәп авылының мәктәптән түбән өлешендәге урам җирләренә килеп урнаша. Башкортстан архивында сакланган документларда Исергәп, авыл буларак, 1795 нче ел белән искә алына: авылда 77 кеше яшәгәнлеге әйтелә, ә инде 50 елдан соң, 1863 елда авылда 331 кеше булуы турында шулай ук документлар бар. Башкортлардан авылның исеме Исергәп (төрки чыганакларда "кызгану" дигән мәгънәне аңлата). Казан якларыннан изелүгә, көчләп чукындырылуга дучар халык безнең төбәкләргә күчеш чорында, 1750нче елларда Арча районы Курсабаш авылыннан 8 гаилә хәзерге Казан урамында урнашып калган (бу урам халык телендә "Казан кешесе урамы" дип йөртелә). Ә инде халык телендә Әтәмби атамасын йөртүче урамга ("Әтәмби"- йорт җире, нәсел-нәсәбе булмаган дигән мәгънәне белдерә) ул чорда типтәрләр дип аталган милли төркем кешеләре урнашканнар (танылган маринист язучы Миргазыян Юныс шушы урамда туып үскән. Аның "Әтәмби хатыннары" дигән истәлек-хикәясе дә бар). 1917 елгы инкыйлабка тикле авылда 3 зур төркем- общество яшәгән: башкорт обществосы, ясаклы татарлар, типтәр обществосы.

Шулай итеп, бүгенге Исергәптә яшәүче татарларны нигездә өч төрле халык вәкилләре барлыкка китергән. Авылга нигез салган башкортлар аерым өстенлекләрдән файдаланганнар, аларның җирләре күбрәк булган, ә инде үз туган –үскән җирләреннән көчләп кузгатылган Казан кешесе, Әтәмби урамнарында гомер сөргән халык хуҗалар булып түгел, ә башкортлар керткән өйдәшләр булып саналганнар.

Милли кием дә һәр төбәкнеке үзенчә булган: башкорт ягыннан килгәннәр, әлбәттә, тәңкәләрдән тезеп эшләнгән түшелдерек, аны муенннан кияләр һәм ул хатын-кызның бөтен күкрәген каплап тора. Шулай ук тәңкәләрдән тезеп эшләнгән сагалдырыйк дигән әйбер, ул зур чуклы яулыкларга тегелә, ике рәт булып муенны тулысынча каплап тора. Бер караганда, моны ислам гадәте дип тә әйтергә була, чөнки мөселман хатын-кызлары күкрәкләрен һәм муеннарын каплап йөрергә тиешләр..

Өс-баш киемнәре ир-атларда:

-киң һәм тезгә кадәр озынлыктагы күлмәкләр;

-ыштан;

-камзул;

-кәзәки;

-эшләпә;

-бишмәт, тун, шарф,

-билбаулар булган.





Авылда элекке киемнәр хатыннар - кызларда:

-төрле-төрле күлмәкләр;

-камзуллар;

-җилән;

-алъяпкыч;

-күкрәкчә;

-яулык;

-итәк.

М.Юныснның “Шәмдәлләрдә генә утлар яна” повестенда Әтәмби карчыкларының киемнәре түбәндәгечә сурәтләнгән:

“Мәҗлескә чакырылу аларның ярты гасыр сандык төбендә тасланып яткан күлмәкләрен кияргә мәҗбүр иткән. Күлмәкләр шундый шәп: Әби патша заманында тукылган сәрпинкәдән тегелгән; яшел бәрхет яка, изү тирәләре укалы; аяк атлавына ияреп, киң итәкләр җилфердәп киткәндә, шомырт чәчәге һәм бал исенә нафталин, такта чәй, кызыл билле прәннек исе кушыла.

Аякларында яфрак бизәкләре төшкән кызыл сәхтиян читек. Җиңел, йомшак, иркен. Биисе килгән чакта алган аяк киеме бит. Әллә шуңа күрә читек киеп җибәрү белән аякларның йөгерәсе килә башлый. Почмаклап бәйләгән яшел кәшимир яулыклар карчыкларның иңендә җиңү әләме шикелле җилфердәп бара. Йөрәкләрдә яшьлек моңы уятып, чәчүргеч таккан талир тәңкәләр чыңлый…”

- Ә ирләрдә камчат бүрек булган. Башкорт ягыннан килгән кешеләр башкорт колакчын бүрекләре кигәннәр. Казан төбәгеннән килүчеләр колаксыз мескен алып килгәннәр. Исергәпнең борынгы ир-атлары бүрекне сарык тиресен иләп тә теккән, әрәмәдә төлке, кондыз күпләп йөргәнлектән, аучылар бүрек читләрен төлке, бүре кондыз тиреләре белән тышлаганнар. Шулай ук ирләрнең җәйге баш киеме эшләпә булган. Аны өйдә ак төстәге сарык йонынннан киез итек басучылар ясаган.



Аларда чиккән әйберләр бик күп, кара һәм кызыл җирлеккә эре-эре чәчәкләр, үсемлек үрнәкләре чиккәннәр, Алар гаҗәеп матур һәм үзенчәлекле, әйтерсең лә кара җирдә үсеп чыккан нәфис гөлләр! Бу күлмәкләр бала итәкле, җиңнәре дә буенча чигелгән, күлмәк өстеннән чиккән алъяпкыч ябылган, түштә - түшелдерек, муенда – сагалдырык, башта – чиккән чәлпәк калфак һәм зур кәшимир-француз яулык, аякта – озын тула оек һәм читек-кәвеш..



Борынгы әбиләребез киемнәрен өйдә тукылган киндердән яки җитеннән һәм өйдә баскан туладан эшләгәннәр. Киндер һәм җитенне кырда игеп үстергәннәр. Барлык кигән киемнәре табигый материалдан булган. Киндер үстереп, көлтәләрне күлгә батырып, аннан алып киптереп- талкып, киндер җепләр әзерләгәннәр.  Өйләр саен диярлек туку станоклары эшләгән, шул станокларда тукыма тукыганнар, киндер ак килеш тә кулланылган, аларны махсус буяулар белән манганнар да. Аннан күлмәк-ыштан, алъяпкычлар, киндер букчалар теккәннәр. Алъяпкычларны милли бизәкләр белән  чиккәннәр, вак чуптар бизәкләр төшергәннәр.

М.Юныснның “Шәмдәлләрдә генә утлар яна” повестенда Әтәмби карчыкларының киемнәре түбәндәгечә сурәтләнгән:

“Мәҗлескә чакырылу аларның ярты гасыр сандык төбендә тасланып яткан күлмәкләрен кияргә мәҗбүр иткән. Күлмәкләр шундый шәп: Әби патша заманында тукылган сәрпинкәдән тегелгән; яшел бәрхет яка, изү тирәләре укалы; аяк атлавына ияреп, киң итәкләр җилфердәп киткәндә, шомырт чәчәге һәм бал исенә нафталин, такта чәй, кызыл билле прәннек исе кушыла.

Аякларында яфрак бизәкләре төшкән кызыл сәхтиян читек. Җиңел, йомшак, иркен. Биисе килгән чакта алган аяк киеме бит. Әллә шуңа күрә читек киеп җибәрү белән аякларның йөгерәсе килә башлый. Почмаклап бәйләгән яшел кәшимир яулыклар карчыкларның иңендә җиңү әләме шикелле җилфердәп бара. Йөрәкләрдә яшьлек моңы уятып, чәчүргеч таккан талир тәңкәләр чыңлый…”


Казан кешесе урманда яшәүчеләрдә Казан татарларына хас киемнәр өстенлек иткән. Киемдәге төсләр аерымлыгы да вариантлар биргән. Киемнең төсе күбрәк хуҗасының яшенә бәйле булган. Мәсәлән, кара казакига күнеккән ир-ат, олыгая төшкәч, казакины ак тукымадан да тектерә. Гомумән, ак төс, башка төрки халыклардагы кебек, сафлык һәм картлык билгесе: кызларда ак калфаклар, ак бәрән туннар, кайбер төркемнәрдә ак чикмән булса, өлкәнрәк яшьтәге хатыннарда ак тастар, ак өрпәк (өчпочмаклы яулык), ак кыекча һ.б. киемнәр булган. Кызыл төс—яшьләргә хас.  Бу бигрәк тә яшь хатыннар киемендә чагылган.  Мәсәлән, кызыл җирлекле күлмәкләр, бөркәнчекләр, кушъяулык. Казан хатын-кызларының аскы баш киеме безнең көннәргә килеп җитмәгән. Аны шактый иртә дүрт почмаклы фабрика яулыклары алыштырган.

Татар халкының традицион-гадәти өс киеме күп төрле булган. Ул эчке һәм тышкы, язгы һәм көзге, җәйге һәм кышкы кием төрләрен үз эченә алган. Һәр төр, кайбер форма үзенчәлекләренә карап, вариантларга бүленгән. Мәсәлән, камзулның түбәндәге вариантларын күрсәтергә мөмкин: озын һәм кыска буйлы, җиңсез, терсәктән җиңле, ябык яки ачык изүле, өч, биш, җиде билле һ.б.





Әмма ирләр ефәктән күлмәк-ыштан кимиләр вә гайре киемнәр һәм кимиләр; ефәк кием кимәк шәригатьтә ирләргә дөрес түгел. Әмма кәләпүшне ефәктән тегеп кияләр, зарар юк. Ирләр ыштаны һәм ситсадан яки башка нәрсәдән, һәрничек фабрикада сугылган нәрсәдән була. Күбрәк ситсадан кияләр; балаклары киң һәм озынлыгы тубыкка чаклы була. Ыштанның төбе киң була һәм бөрмә дип әйтәләр, шул бөрмәгә тасмадан бау тагыла. Шул тасма бау белән ыштанны җыеп бәйлиләр.



Безнең Исергәп авылы халкы ярлы булса да, татар милли киемнәрендә йөрергә тырышкан. Киемнәр киндердән, йоннан булган. Аеруча үзенчәлекле булганнарын мин мәктәпнең “Туган якны өйрәнү” музееннан алып өйрәндем. Бу музейны оештырганда, укучылар авыл буенча йөреп, әби-бабайлардан калган киемнәрне җыйдылар. Алар бүген музейның “Борынгы авыл күренеше” экспозициясендә урын алган.

Казан хатын-кызларының баш киеме безнең көннәргә килеп җитмәгән. Аны шактый иртә дүрт почмаклы фабрика яулыклары алыштырган.



Исергәп хатын-кызлар киеменең иң күркәм өлеше француз яулык ( зур кызыл чәчәкле ал төстәге юка яулык), бәбәй итәкле күлмәк, укалы камзол, чулпылар булган.



Хатын-кыз күлмәге:


Хатын-кызларның борынгы стильдәге күлмәге тоташ яки өзек буйлы, такма итәкле итеп тегелгән һәм төрле декоратив алымнар белән бизәлгән.

Күкрәкчә:

Хатын-кызларның борынгы киеменә бигрәк тә хас нәрсә - күкрәкчә. Аны хатыннар күлмәк астыннан муеннарына бәйләп калдырганнар.

Исеменнән үк билгеле, ул хатын-кызларның күкрәген эчке яктан каплап торган.







Күлмәк-ыштанга якын нәрсә — алъяпкыч булган. Аны ирләр дә, хатыннар да үз иткән. Исергәп халкы өчен ул эш киеме генә түгел, ә көндәлек кием булып та саналган. Печән һәм урак вакытларында кызлар һәм яшь киленнәр күлмәк өстеннән чиккән алъяпкыч бәйләгәннәр. Ир-атлар киндер алъяпкыч белән тимерчелектә дә, кырда да эшләгәннәр.



Борынгы әби-бабайларыбызның эчке киемнәреннән берсе –ыштан. Тегелү рәвеше ирләр өчен дә, хатын-кызларга да бер төрле булган. Борынгы тормыш-көнкүрешкә җайланып: идәнгә, сәкегә аяк бөкләп утыру өчен җайлашкан. Аны өйдә сугылган киндердән теккәннәр. Сәүдә белән читкә чыккан кешеләр алача дигән үзбәк материалы алып кайтканнар, соңрак аңардан тегә башлаганнар.







Борынгыларның аяк киемнәренең бер өлешен тула оек, киез итекләр алып торган. Ирләр һәм хатыннар кышын киез итек кигәннәр. Итекнең озын кунычлысы, кыска башмак кебек эшләнгәннәре булган. Кыска кунычлы киез итекләр яратып киелгән, чөнки абзар-курага кереп - чыгып йөрү өчен уңайлы.








Казан татарлары Исергәп авылына күн аяк киеменең таралган төре- читекне алып килгәннәр. Читекне ирләр дә хатын-кызлар да кигән: ирләр кара күннән, хатын-кызлар каюлы үкчәле читекләр кигәннәр. Башкортлардан күн кәвеш каталар кергән. Аны калын күннән, калын олтанлы итеп теккәннәр. Каталарны тула оек белән кигәннәр. Хатын-кызлар өчен башмаклар да теккәннәр, соңрак бәрхет башмаклар кия башлаганнар. Ә безнең авыл халкының төп аяк киеме чабата булган. Урманда юкә күп үскән, аны кисеп алып кайтып суга батырып, юкә мунчала алганнар, шуңардан чабатачылар төрле кеше дә киярлек чабаталар үргәннәр. Яңгырда, карда кияр өчен күтәртмәле чабата үргәннәр. Аны күбрәк тула оек өстеннән кигәннәр. Исергәптә Чабатачы Әхми нәселе билгеле булган.



Борынгы милли киемнәрне саклаучы Камил абый тегүче әнисе турында шигырь юлларын яза:

Гади колхозчы әнием
Данлы тегүче хатын.
Юрганнар сырып җылытты
Тирә-як авыл халкын.
Закир кызы –Саимә
Мирзаҗан кызы булган.
Итек баскан, чыпта суккан ,
Гомере эштә үткән.
Көндезен колхозда эшли,
Киндер йолка, сүс талкый,
Төннәрен арбасын тартып,
Сазлыктан күрән ташый.

# Йомгаклау

К.Насыйриның “Татар этнографиясе материаллары” хезмәтен өйрәнеп, татар милли киемнәренә, аларның килеп чыгышларына тегелү рәвешләренә, ир-ат, хатын-кыз киемнәренең аермалыкларына игътибар итәргә туры килде. Галим яшәгән чордан алып, Бөек Ватан сугышына кадәр югарыда карап киткән киемнәр авылларда өстенлек иткән. Бүген бу киемнәрне рәсемнәрдән һәм спектакльләрдән һәм мәктәп музейларыннан гына күрергә мөмкин. Исергәп авылына беренче килеп утырган кешеләрнең кайсы төбәктән булулары да кием үзенчәлекләренә тәэсир иткән. Борынгы кием үрнәкләре сакланып калмаса да, мөрәҗәгать иткән белешмәләргә таянып, бераз күзаллау тудырырга мөмкинлек туды. Элекке заманнарда татар халкының киемгә материалны үзенең үстереп-эшкәрткәне, аны теккәне, чиккәне билгеле. Безнең авыл халкы да шундый булган. Музей экспонатлары шуны дәлилли.



Исергәп урта мәктәбенең музеенда шулай ук әби-бабаларыбызның кадерле киемнәре саклана. Борынгы өй күренеше, татар авылы ихатасы экспозициясендә борынгы халыкның кул эшләренә оста булуын, өй кирәк-яракларын, көнкүрештә куллану өчен коралларны да үзләре ясаганы күренә.Ул чор киемнәренә халкыбызның күңел җылысы, күз нурлары, зәвыгы тирән салынган. Борынгы чигү, тегү үрнәкләре зур тәрбия чарасы булып тора. Ел саен сабантуйларга әзерләнгәндә, бу киемнәр киштәләрдән төшәләр. Борынгы чорны сурәтләгән тамашаларда, мәктәп спектакльләрендә дә борынгы киемнәрне кулланырга туры килә. Хәтта Курган, Екатеринбург сабантуйларына да Исергәп урта мәктәбенең музеennан алган киемнәрдә бардылар.  Концерт, тамашаларда гына киелә торган милли киемнәребезне гадәти, көндәлек киемнәр рәтенә кертеп җибәрсәң, бик тә күркәм булыр иде. Кызларыбыз да әбиләребез кебек чигү, тегү, бәйләү эшләренә ныграк җәлеп ителерләр иде. Чөнки хатын-кызның уңганлыгы кул эшләрен ничек белүгә карап та бәяләнә. Ә ир-ат өчен җитмеш төрле һөнәр белү шул чакта дәлилләнер иде.





# Кулланылган әдәбият


1. Декоративно-прикладное искусство казанских татар. - Москва, Советский художник, -1990. -64-66 с.
2. Исергәп урта мәктәбенең музей материаллары.
3. Мөхәммәдова Рәмзия Татар халык киемнәре. – К.: Тат.кит.нәшр., 1997. - 80-88 б.
4. Каюм Насыйри.1-том. – К.: Тат.кит.нәшр., 1974. -93-99 б.
5. Сергеева Нурзия Г. Тылсымлы бизәк. –К.: Тат.кит.нәшр., 1997. – 4-7 б.
6. Tartarica - Атлас. – Казань –Москва - Санкт-Петербург, -2000. -438-441 с.
7. Р. Фәхреддин. Болгар һәм Казан төрекләре. –К.: Тат. кит. нәшр., 1993. -28-34 б.
8. http://tt.wikipedia.org/wiki/ Татар милли киемнәре